…ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СЫЗЫП АК НУР БЕЛӘН!

# Караш

1999 нчы елның 19 нчы маеннан чыга.
№5 2013. Гыйнвар

## «НӘШРИЯТ ЭШЕ» түгәрәге

## БЕЗНЕҢ УҢЫШЛАРЫБЫЗ

***Чебешләрне көзен санийлар дисәләр дә, мәктәптә киресенчә, кышын һәм язын санийлар. Дөрес, чебешләрне түгел, ә уңышларны. Ниһаять ноябрь, декабрь айларында булып узган фән олимпиадаларының район туры нәтиҗәләре билгеле булды. Быел безнең 7 җиңүчебез һәм 8 призерыбыз булды. Нәтиҗәләр түбәндәгечә:***

| № | Фән исеме | Сыйныф | Урын | Укучының исеме | Укытучы исеме |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Физик мәдәният | 8 | 3 | Зиннуров Зөлфәт | Билялов Ф.Т. |
| 2 | Биология | 11 | 3 | Зиганшина Рузилә | Мубаракшин И. |
| 3 | Җәмгыять белеме | 11 | 2 | Закирова Алия | Мубаракшин И. |
| 4 | Хокук белеме | **11** | **1** | **Мубаракшина Миләүшә** | **Мубаракшин И.** |
| | | **9** | **1** | **Закирова Миләүшә** | **Мубаракшин И.** |
| 5 | Геология | **11** | **1** | **Мубаракшина Миләүшә** | **Мубаракшин И.** |
| 6 | Татар теле | **9** | **1** | **Газимҗанова Рания** | **Газимҗанова Р.** |
| | | **10** | **1** | **Валеева Миләүшә** | **Газимҗанова Р.** |
| | | 10 | 2 | Галимова Миләүшә | Газимҗанова Р. |
| | | 11 | 3 | Гиниятуллина Рузилә | Гайсина Г. |
| 7 | Татар әдәбияты | **10** | **1** | **Галимова Алсинә** | **Газимҗанова Р.** |
| | | 9 | 2 | Газимҗанова Рания | Газимҗанова Р. |
| | | 10 | 3 | Галимов Алмаз | Газимҗанова Р. |
| | | 11 | 3 | Абдуллина Илүсә | Гайсина Г. |
| **8** | Математика | **6** | **1** | **Ерошкина Елена** | **Сруртдинова Л.** |

***Моннан тыш әле чит телдән, экономикадан да район күләмендә иң күп балл җыючылар да бар. Шулай шул, тырышлык бушка китми, шундый нәтиҗәләр булганда укырга да кызык. 1 нче урынны алган укучыларыбызга олимпиаданың республика турында уңышлар телибез. Район данын яклап, җиңүләр яулап кайтсыннар алар!!!***

## *ДУМА ЯҢАЛЫКЛАРЫ*

**Үткән атнада дума тарафыннан берничә акция уздырылды. Кабат “Икеләрсез атна” акциясе узды, бу юлы “чемпион” титулын 9 нчы А сыйныфы 20 “икеле” белән алды, бөтен мәктәпне шаккаттырды. Шулай ук экология юнәлешендә “Кошларга кышларга ярдәм ит” проекты кысаларында җимлекләр ясау дәвам итә. “Созвездие – Йолдызлык” фестивалендә дә әзерлек башланды. Номерлар сайлап алына, осталар үзләренең репетицияләрен башлап җибәрде.**

*БУ АЙДА… мәктәбебездә Республика күләмендә ату ярышлары булып узды.*

*БУ АЙДА… фән олимпиадаларының республика туры башланып китте. Катнашучыларга уңышлар телибез*

*БУ АЙДА… 19 нчы гыйнварда безнең йөүчеләр районда иң осталары булып танылып 1 нче урынны алдылар*

## КҮП УКЫГАН - КҮП БЕЛГӘН

Безнең Лашман урта гомубелем бирү мәктәбе китапханәсе әдәби китапларга бик бай. Кызыклы чит ил әдәбияты, маҗаралы әсәрләр, татар һәм рус классиклары әсәрләре күп. Китапханәдән даими файдаланып үз белемнәрен тирәнәйтүче укучыларыбыз да шактый. Әйтик, 11 нче сыйныф укучысы Вагизова Фәния. Ул рус әдәбиятыннан Бердәм Дәүләт имтиханнына әзерләнә, шуңа да китапларны күп укый, әзерлек барышында килеп туган сорауларга җавап эзли.

Яңа гына мәктәпкә килеп кергән булуларына карамастан, беренче сыйныф укучылары Мубаракшина, Закирова, Талиповалар инде 5-6 китап укырга да өлгергәннәр икән. 2 нче сыйныфтан Асылгәрәева Камилә, Гатина Диләрә; 3 нче сыйныфтан Гайсина Русинә, 4 нче сыйныфтан Сафиуллина Зөһрә, 5 нче сыйныфтан Архипова Раилә, Гимранова Алсу, 6 нчы сыйныфтан Ерошкина Елена, Хәмидуллина Айгөлләрне чын мәгънәсендә китап сөючеләр дип була. Алар китапханәгә еш йөриләр. Тик менә 7, 8, 9 нчы сыйныфлар арасында китапханәгә китап кирәксенеп керүчеләр, әдәби әсәрләр алып укучылар аз. Кайбер сыйныфларда бер әдәби әсәр дә алып укымаучылар бар. Бәлки алар китапханәнең кайда урнашуын белмиләрдер? Хөрмәтле укучылар, әдәби әсәр нинди генә телдә язылган булса да, күп мәгълүмат бирә, тормышка әзерли, үз фикереңне булдыруга һәм аны җиткерә белүгә ярдәм итә. Китап сөюче бер кайчан да хур булмас.Сез беләсез, Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай, рус халкының даһи язучылары А. С. Пушкин, М. Горький китапны яратырга, күп укырга өндәгәннәр. “Китапны яратыгыз – ул белем чишмәсе” (М. Горький). Китап кеше тормышында тәрбияче дә, киңәшче дә, ярдәмче дә, таяныч та була ала. Кызыклы, мавыктыргыч әсәр укыганда геройлар язмышы өчен борчыласың, кайсыдыр геройны ачуланасың, ә кайсынадыр ошарга омтыласың. Ә андый мавыктыргыч, кызыклы әсәрләр безнең китапханәдә күп, бары тик үз зәвыгыңа туры китереп сайлап алырга, укырга гына кала. Кызыклы китап, әсәр уку кайберәүләр өчен тәмле ризык ашаган кебек. Китапханәдә сезне көтеп калабыз.

***Китапханә Советы.***

## Казанда, Чыршы бәйрәмендә

*26 нчы декабрь көнне Казанның “Татнефть-арена” боз сараенда Татарстанның балалар өчен төп Яңа ел чыршы бәйрәме узды. Анда булырга миңа да язды. Боз сарае Яңа ел чыршы бәйрәменә килүче балалар белән шыгрым тулып, гөж килде.*

*Татарстанның төп чыршы бәйрәме меңләп тамашачыны үзенә җыйды. Яңа ел тамашасы бик матур ике катлы сәхнәдә барды, җырлы-биюле чыгышлар булды. Аннары сәхнәгә төп каһарманнар – Кыш бабай һәм Кар Кызы чыкты. Алар да оста итеп чыгыш ясадылар. Кыска гына булсалар да, кызык конкурслар үткәрелде. Тамаша ахырында Чыршы бәйрәме кунаклары өчен «Пицца» группасы үзләренең җырлары белән чыгыш ясады. Барлык балалар да татлы күчтәнәч белән кайтып китте. Мин бу бәйрәмнән бик канәгать булып кайттым.*

***Ленара Зиганшина 11 нче сыйныф укучысы***



# Минем буш вакытым - минем сәламәтлегем



Ярыш мизгелләре





## АЛДЫМ ҖӘЯ, ТОТТЫМ УК...

Ярты ел чамасы элек, безнең мәктәптә җәядән ату спорт төре белән шөгыльләнә башладык. Нинди спорт төре соң бу? Беренче карашка бик гади, җиңел генә кебек. Ләкин эченәрәк кергән саен аның алай түгеллеген аңлыйсың. Иң беренче җәяләр. Алар бәләкәй чакта сыгылмалы таллардан бөгеп ясап уйнаганнардан нык аерыла. “Җилкәләр” тоткага беркетелә һәм тетева белән тоташтырыла. Укны аткач барлыкка килгән дерелдәвекне киметү өчен махсус таяк беркетелә. Тотка өстендә киштә – ук куйгыч. Болар җәянең төп өлешләре, тагын плунжер, кликер дигән әйберләр дә була. Ук исә койрыкчадан һәм очлыктан тора, койрыкча янында “каурыйлар” бар.

Бу спорт төре баш миендәге нейроннар үсешенә тәэсир итә, игътибарлылык артуга сәбәп була ала. Бу хакта пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе һәм рәхмәте булсын) әйткән: “Аллаһ искә төшерелмәгән һәрбер әйбер хуп күренми. Дүрт әйбердән кала: ир-атның уктан атуы, ат өйрәтү, гаилә белән уеннар, йөзәргә өйрәнү”. Димәк, бу кызыклы спорт төре бик файдалы да икән әле. 8, 9 нчы гыйнвар көннәрендә мәктәбебездә җәядән ату спорты буенча ярышлар булып узды. Безнең командадан Мөхиббуллин Искәндәр, һәм Зөфәрова Ләйлә призлы урыннар иясе. Әйе, бары тырышырга гына кирәк, тырышлык исә беркайчан да бушка китми.

***Тимербулат Билялов 9 нчы сыйныф укучысы***

**“Караш” газетасының әлеге саны өчен җаваплы: Газимзянова Р. Ф.**
**Хәбәрләшү өчен телефон: 9270444015**